КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 апрель г.Казань № 276

Сосновский балтырганын юкка чыгару чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Сосновский балтырганын юкка чыгару чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 23 апрель, 276 нчы
карары белән расланды

Сосновский балтырганын юкка чыгару чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр, җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү кысаларында даими файдалану хокукында хуҗалык субъектларына бирелгән кишәрлекләрдән тыш, муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә үсә торган Сосновский балтырганын юк итү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү тәртибен (алга таба - муниципаль берәмлекләр, субсидияләр, Сосновский балтырганын юкка чыгару чаралары) билгели.

Әлеге Кагыйдәләрне куллану максатларында Сосновский балтырганын юкка чыгару чаралары дигәндә механик (кул һәм (яисә) механик чаптыру, бульдозер кисентесе, фреза белән эшкәртү һәм башка чаралар) һәм (яисә) Сосновский балтырганы белән чүпләнгән территорияләрне химик (гербицидлар белән) эшкәртү чаралары комплексы аңлашыла.

2. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба - Министрлык) китерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчегә кадәр әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

3. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тиешле муниципаль районда Министрлыкның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре белгечләре һәм шәһәр округларында Министрлык вәкилләре, шулай ук «Россельхозцентр» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы хезмәткәрләре катнашында Сосновский балтырганы белән чүпләнгән мәйданнарны билгеләү өчен комиссияләр төзиләр.

4. Сосновский балтырганы белән чүпләнгән мәйданнар булу субсидия бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерие булып тора.

Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары чираттагы финанс елына кадәрге елның 1 сентябренә кадәр Министрлыкка Сосновский балтыганы белән чүпләнгән мәйданнар турында әлеге Кагыйдәләргә кушымта нигезендә формада Сосновский балтырганын юк итү чараларын үткәрүгә чыгымнарның планлаштырыла торган күләме турында мәгълүмат тапшыра.

5. Тиешле финанс елына ($C_i$) i-муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = V_o \times \frac{\frac{S_i \times Y_i}{100}}{\sum_{i=1}^{n}(\frac{S_i \times Y_i}{100})},$$

монда

$V_o$ - әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган муниципаль берәмлекләр бюджетларының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга ассигнованиеләр күләме;

$S_i$ - i-муниципаль берәмлектә Сосновский балтырганы белән чүпләнгән территорияләрнең гомуми мәйданы, гектар;

n - Сосновский балтырганы чүпләп алган мәйданнар турында мәгълүмат биргән муниципаль берәмлекләр саны;

$Y_i$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең (алга таба – Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләре) 13 пункты нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашуның иң чик дәрәҗәсе.

6. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләр бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

7. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма буенча Субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы арасында төзелә торган субсидия бирү турындагы килешү (алга таба - килешү) нигезендә бирелә.

8. Субсидия бирү шартлары түбәндәгеләр була:

финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган чаралар исемлеген һәм чараларны уздыру тәртибен раслый торган муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты булу;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максатларында субсидия бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган субсидия күләмен кертеп) булу;

финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлекнең йөкләмәләрен үтәүне күздә тоткан килешү төзү һәм күрсәтелгән килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

9. Әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында билгеләнгән критерийга туры килә торган субсидия алу өчен муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәге документларны җибәрә:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә гариза;

вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган субсидияне үз эченә алган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының кабул ителгән карарыннан өземтә;

финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган чаралар исемлеген һәм чараларны уздыру тәртибен раслый торган муниципаль берәмлекнең муниципаль хокукый акты күчермәсе;

10. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидия чараларын санау Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль берәмлекнең финанс органына ачылган муниципаль берәмлек бюджетының бердәм счетына гамәлгә ашырыла.

11. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлекнең әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән шартларга туры килмәве;

әлеге Кагыйдәләрнең 9 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

әлеге Кагыйдәләрнең 9 пунктында билгеләнгән срокны бозып документларны тапшыру.

12. Субсидияләрдән файдалану нәтиҗәсе - муниципаль берәмлек территориясендә Сосновский балтырганын юкка чыгару чаралары башкарылган җир кишәрлекләре мәйданы (гектарларда).

13. Субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә каралган субсидияләрдән файдалану нәтиҗәсенең мәгънәләре белән агымдагы финанс елы өчен субсидияләрдән файдалануның факттагы ирешелгән мәгънәләрен чагыштыру юлы белән башкарыла.

14. Муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары агымдагы финанс елының 31 декабреннә дә соңга калмыйча Министрлыкка килешүдә каралган форма, вакытлар һәм тәртип буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган муниципаль берәмлекләр бюджетлары чыгымнары һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәсе мәгънәләре турында хисаплар тапшыра.

15. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрнең максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

16. Килешүдә каралган йөкләмәләрне бозган очракта, муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына акчаны кире кайтару һәм шартлары Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 15 – 18, 23 нче пунктларында билгеләнгән.

17. Бу Кагыйдәләр нигезендә алынган, агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субсидия агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемено күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемено, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Кагыйдәләр һәм килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидияләр максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

20. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелгән субсидиядән максатчан файдалануны, әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән субсидия бирүнең шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Сосновский балтырганын юкка чыгару чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә кушымта

Форма

## Татарстан Республикасында Сосновский балтырганы белән чүпләнгән мәйданнар һәм Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар уздыруга чыгымнарның планлаштырыла торган күләмнәре турында мәгълүмат

___________________________________________________________
(муниципаль район / шәһәр округы исеме)

| Торак пунктның исеме | Чүпләнүнең гомуми мәйданы, гектар | Күп үскән урын (юллар, чокырлар буйлары, су фонды территориясе, урман фонды территориясе һ.б.) | Кадастр номеры | Геолокация ноктасы | Җир кишәрлеге категориясе | 20_____ елда планлаштырыла торган эшкәртү, гектар | | | Сосновский балтырганын юкка чыгару чараларын үткәрүгә муниципаль район бюджеты акчалары исәбеннән 20____ елда планлаштырыла торган чыгым күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | барлыгы | механик | химик | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы муниципаль районының / шәһәр округының җирле үзидарә органы җитәкчесе

_____________ _______________________________________ _____________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы) - булган очракта) (дата)
М.У.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы/Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы вәкиле

_____________ _______________________________________ _____________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы) - булган очракта) (дата)
М.У.

«Россельхозцентр» ФДБУнең Татарстан Республикасы филиалы район бүлеге җитәкчесе

_____________ _______________________________________ _____________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы) - булган очракта) (дата)
М.У.

___________________________________________